СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-30 «17» декабрь 2018 ел

Мамадыш муниципаль районында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча федераль һәм республика законнарын гамәлгә ашыру барышы турында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районында «Забота» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры Г.И. Давыдованың Мамадыш муниципаль районында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча федераль һәм республика законнарын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районында «Забота» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры Г.И. Давыдованың Мамадыш муниципаль районында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча федераль һәм республика законнарын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районында «Забота» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарның яшәү шартларын яхшырту максатларында түбәндәге эшләрне дәвам итәргә:

- муниципаль район территориясендә халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең үтемлелеген, сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү буенча;
- өлкән буын һәм инвалидларның матди һәм социаль хәлен күтәрү өчен шартлар тудыру;
- социаль хезмәт күрсәтү өлкәсенә бизнесны һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларны, хәйриячеләрне һәм волонтерларны җәлеп итү буенча эш алып баруны.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://mamadysh.tatarstan.ru. веб-адресы буенча игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов